КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 апрель г.Казань № 222

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2016 ел, 15 гыйнвар, 13 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2016 ел, 15 гыйнвар, 13 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 ноябрь, 831 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, 646 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәнең 5 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Уртак файдаланудагы территориягә керми торган һәм барлыкка килгән төзелешнең ташкы архитектура күренеше үзгәрүгә китерми торган инженер инфраструктурасы объектларны һәм өстәп төзелгән бүлмәләрне карап тикшерү Комиссия вазыйфаларына керми.»;

әлеге карар белән расланган Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзү эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составында:

составтан А.К.Әйзәтулловны, Г.Н.Айдарованы, Е.П.Прокофьевны чыгарырга;

составка түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Бакулин Герман Алексеевичны | «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе проектларының баш архитекторын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Варакин Евгений Анатольевичны | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты җитәкчесен (килешү буенча) |
| Җаббаров Марат Азат улын | «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгын (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгын |
| Саначин Сергей Павловичны | Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге идарәсе һәм Бөтенроссия тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау җәмгыятенең Татарстан төбәк бүлеге әгъзасын (килешү буенча) |
| Токарева Гөлсинә Шәүкәт кызын | «Архитекторлар Токаревларның иҗат остаханәсе» ҖЧҖ баш архитекторын (килешү буенча) |
| Хафизова Наилә Наил кызын | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең Казан шәһәре буенча архитектура һәм мәдәни мирас һәйкәлләрен саклау бүлеге башлыгын (килешү буенча); |

Новиков Николай Михайлович вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге архитекторы Н.М.Новиковның шәхси иҗат остаханәсе» ҖЧҖ директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин